**ГЛАВА**
**НОВОШЕШМИНСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЯҢА ЧИШМӘ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2023 елның «03» ноябреннән № 48

2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 19 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2019 елның 24 октябрендәге 53-325 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмә»се, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябрендәге 14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә»се нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында яшәүчеләрнең 2024 елга һәм 2025, 2026 еллар план чорына бюджет проекты турында фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында карар бирәм:

1. Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында»гы карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2023 елның 22 ноябрендә 17.00 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет ур., 80 нче йорт, адресы буенча

урнашкан Яңа Чишмә муниципаль районы Советының актлар залындаТатарстан үткәрергә

Гавами тыңлаулар тәртибе Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 30 сентябреннән14-105 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы 2021елның 12 октябрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru/ бастырылган нигезләмәгә туры китереп тормышка ашырыла.

2. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында»гы Карары проектына тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен расларга (кушымтада бирелә).

3. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлегенә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрүне, гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими депутат комиссиясенә «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Карары проектын, гавами тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, эшләп бетерергә һәм 2023 елның 07 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышында карауга кертергә.

5. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча комиссиясе рәисенә йөкләргә.

Башлык В.М. Козлов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль
районы Башлыгының
2023 елның «03» ноябрендәге
48 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы бюджеты турында» карары проектына кертелә торган үзгәрешләр һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибе

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының 2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына бюджеты проектына кертелә торган үзгәрешләр проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советына түбәндәге адрес буенча кертелә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Совет ур., 80 каб. № 314 язма рәвештә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының оештыру бүлеге башлыгына.

Тәкъдимнәр эш көннәрендә 08.00 сәгатьтән 16.30 сәгатькә кадәр, «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырылган көннән алып кабул ителә.

2. Гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча кабул ителә: 423190, Татарстан Республикасы, Яңа Чишмә районы, Яңа Чишмә авылы, Совет урамы, 80 нче йорт, каб. № 314, шәхсән яки почта аша (конвертта «Бюджет турында фикер алышу» тамгасы белән).

Башлык В.М. Козлов